**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Совет**
**Борискинского сельского поселения**
**Алькеевского**
**муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Әлки муниципаль районы**
**Борис авыл җирлеге**

**Советы**

Адрес: 422883, РТ, с. Борискино, ул. Дружбы , 8

тел: 8 (84346) 76-239

Адресы: 422883, РТ, Борис авылы, Дуслык ур.,8

факс: 8 (84346) 76-239

**РЕШЕНИЯ** с.Борискино **КАРАР**

2015 елның 26 января № 129

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Борис авыл җирлеге Советы КАРАРЫ

Ташбилге авыл җирлеге башлыгының «2014 елда Борис авыл җирлегенең социаль-икътисадый үсеш йомгаклары һәм 2015 елга бурычлар турында» хисабы.

Борис авыл җирлеге башлыгы Г.В.Самарина «Борис авыл җирлеге башлыгы хисабы 2014 ел йомгаклары буенча башкарылган эшләр турында»докладын тыңлап фикер алышканнан соң

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Борис авыл җирлеге Советы КАРАР ИТӘ:

1. Ташбилге авыл җирлеге башлыгының «2014 елда Борис авыл җирлегенең социаль-икътисадый үсеш йомгаклары һәм 2015 елга бурычлары турында» хисабын игътибарга алырга.
2. 2014 ел йомгаклары буенча Борис авыл җирлеге башлыгы эшен канәгатьләнерлек дип санарга.
3. Халыкның тормыш дәрәҗәсен һәм сыйфатын күтәрүне алга таба да мөһим бурыч дип санарга, моның максатларында нәтиҗәле чаралар күрергә:
   - халыкны эш белән тәэмин итү һәм җирлекләрнең икътисадын ныгыту максатларында, район авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе белән берлектә, 2011-2015 елларга кабул ителгән авыл җирлекләре территорияләрен социаль-икътисадый үстерү программасын эзлекле рәвештә үтәүне дәвам итәргә;
   - стабильләштерү финанс хәле өчен җылылык һәм энергетика ресурсларын экономияле файдаланырга, чыгымнарны оптимальләштерү

буенча максатчан эшне дәвам итәргә һәм салымнарны тулысынча җыюга ирешергә.

- шәхси ярдәмче хуҗалыкларда авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү өчен шартлар тудыру, авыл халкына җитештерелгән продукцияне сатарга ярдәм итү, хуҗалыкларда терлекләрнең баш санын арттыруга ирешү, гаилә фермалары төзүдә шәхси хуҗалыкларга һәрьяклап ярдәм күрсәтү.
- авылда кече эшкуарлык шартлары тудырырга һәм халыкны эшкуарлыкны үстерү буенча Россия һәм республика программаларында актив катнашуга җәлеп итү буенча агитация-аңлату эшләре алып барырга.
- урыннарда әхлакый, физик тәрбияне яхшырту, сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау, халыкның ялын оештыру буенча максатчан эш алып барырга,
- халыкка нәтиҗәле һәм сыйфатлы медицина ярдәменнән файдалануны арттыру, балалар авырулары профилактикасын үткәрү чараларын күрергә;
- авылда ял итүне, массакүләм спорт һәм физкультура-савыктыру эшен оештыру өчен шартлар тудырып, мәдәниятне, балалар һәм яшьләр мәгарифен алга таба үстерүне тәэмин итәргә;
- хәйрия эшчәнлегенә ярдәм итү һәм аны үстерү буенча гамәлгә ашыруны дәвам итәргә;
- хокук бозуларны профилактикалау буенча халыкны, иҗтимагый оешмаларны җәлеп итеп, профилактик эшнең нәтиҗәле формаларын эшләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Борис авыл җирлеге башкарма комитетына йөкләргә.

Борис авыл җирлеге Советы Рәисе Г.В.Самарина